Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче
Торнаташ авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел № 03

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

## КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге составына керүче Торнаташ авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 14 ноябрендәге 01 номерлы гражданнар җыены карарына:

«-су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (торбалар, йозаклар, коелар бөҗралары, коены каплау плитәләре, Торнаташ авылы коелары төбендәге плитәләр сатып алу);

-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электроматериаллар сатып алу, Торнаташ авылының урам яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру)».

2) 1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 14 ноябрендәге 01 номерлы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Торнаташ авылында гражданнар җыены карарына:

«-су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Торнаташ авылын су белән тәэмин итү);

-тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (торбалар, йозаклар, коелар бөҗралары, коены каплау плитәләре, Торнаташ авылы коелары төбендәге плитәләр сатып алу».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат

стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Иске Абдул авыл җирлеге Башлыгы Р.Х.Сафина